ISSN 0868-4545



Салават күпере



Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.

Габдулла ТУКАЙ.



Габдулла ТУКАЙның туына – 120 ел

Әйе, халкыбызның сөекле улы – бөек Шагыйребез, мәшһүр Тукаебызның тууына ошбу елның апрель аенда 120 ел тула.

Әйдә, дускай, Шагыйребезнең гомер сәхифәсен янә бер кат күздән кичерик әле:

Габдулла Тукай 1886 елның 26 апрелендә Кушлавыч авылында Мөхәммәтгариф мулла гаиләсендә дөньяга килә. Габдуллага 4 ай булганда әтисе, 3 яшь тә 9 ай чагында әнисе Мәмдүдә вафат була.

Ятим Апушның балачагы Кушлавыч, Өчиле, Кырлай авылларында һәм Казан, Җаек (Уральск) шәһәрләрендә уза.

Шагыйрь гомере, ни кызганыч, кыска була. Әмма шул кыска вакыт эчендә дә ул балалар өчен күп санлы әкиятпоэмалар, шигырьләр, мәсәлләр иҗат итеп калдыра.

Г.Тукай 1913 елның 15 апрелендә кичке 8 сәгать 15 минутта күзләрен мәңгегә йома...

Шагыйрьнең үлмәс сүзләре һәрдаим күңелебездә яңгырый:

Сөй гомерне,
Сөй халыкны,
Сөй халыкның дөньясын...

Әйдә, Тукай, безнең белән бергә
Син дә шатлан, халкың шатлана;
Дәртле Казан, нурлы Казан балкый,
Бездә бүген бәйрәм, тантана!

Нури АРСЛАН.

Габдулла ТУКАЙ

Карлыгач

Күптән түгел безнең тәрәзә капкачын
Оя итте минем сөйгән Карлыгачым.

Ул көн буе аузы берлән балчык ташый,
Балчык берлән матур итеп оя ясый.

Күп эшләде иренмичә; бара-бара
Чыгарды ул матур-матур балалар да.

Ачыксалар Карлыгачның балалары,
Чебен-черки тотып кайта аналары.

Карлыгачым ямьсез озын кара төндә
Каты йоклый оясында, алмый тын да;

Бер канатының астына тыга башын,
Уянмый ул, – бөтен кеше тавышласын,

Күк күкрәсен, ялтыр-йолтыр
килсен яшен,
Төн буена нинди каты җил исмәсен, –

Ни булса да, бары да бер аның өчен, –
Уянмый ул, селкетми дә борын очын.

© "Салават күпере", 2005 ел

Бишек жыруы

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тыршып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Йокла, угълым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.

Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем;
Сиңа теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.

Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син;
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!



Рәссам Алла АЙСИНА



Әтәч илә Күке

– И сөекле Әтәч, нинди матур сайрыйсың!

– Ә син, Күкеҗан, бигрәк моңлы, бигрәк күңелле җырлыйсың! Синдәй сайраучы бөтен дөнья урманнарында да булмас. Аһ! Синең җырлавыңны үлгәнче тыңлап кына торыр идем. Менә, билләһи, ант итәм. Әгәр син сайраудан туктасаң, тагы кайчан гына сайрый башлар икән дип көтәмен. Минемчә, синең тавышың янында Сандугач тавышы бөтенләй югаладыр; белмим, оҗмах кошлары сиңа пар була алырлар микән?..


Бу макташуны читтән тыңлап торган Чыпчык, Әтәчнең сүзен бүлеп:

– Сез, дустлар, бер-берегезне макташып киерелсәгез дә, музыкаңыз һаман борынгыдыр, – диде.

* * *

Ни өчен, Алладан курыкмыйча, Күке Әтәчне мактый? Аның өчен Әтәч Күкене мактый.





Каз

Каз, суда Йолдыз шәүләсен күргәч, Балык дип белде һәм ничә мәртәбә аны ауламакчы булып тырышса да, шәүлә урыныннан кузгалмагач, Каз да шәүлә икәнен белде дә аулауны ташлады.

Иртәгесен Каз суда чын Балыкны күргән иде, ну, бу да кичәге кеби шәүләдер дип, ауламады вә аңар әйләнеп тә карамады.

* * *

Безгә дөрестне яңлыштан һәрвакыт аерырга кирәк, бу икенең берсен берсе урынына төшермәскә тырышырга кирәк.

Ташбака илә Куян

Ташбака илә Куян, узышмакчы булып, бер тауга таба йөгерешә башладылар.
Куян, үзенең йөгереклегенә ышанып, юлда ятып йоклады.
Куян берзаман йокысыннан уянып караса, Ташбака әллә кайчан тауга барып җиткән!
Инде безнең Куян артка калганына үкенде дә, хурланды да, әмма ни файда?

* * *

Көчлегә үзендәге көчкә ышанырга ярамый. Кечкенә генә дошманга да зур дошманга хәзерләнгән кеби хәзерләнергә тиеш.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ





Тычкан илә Күсе

– Күрше! Син бер шатлык хәбәр ишеттеңме? Мәче Арыслан тырнагына эләккән, ди, – дип, Тычкан йөгереп килеп, Күсегә әйткәч, Күсе:

– Шатланма, күз нурым! Әгәр Мәче Арыслан тырнагына якынлашса, бер дә шиксез, Арысланны да һәлак итәр, Мәчедән көчле хайван юк, – диде.

* * *

Куркак берәүдән курыкса, үзе курыккан кешегә бөтен дөнья курку күзе берлән карый дип уйлый.



Исемдә калганнар

(Өзек)

Бу Кырлайдагы беренче кышым үтте. Яз җитеп, карлар эри башлады. Озакламый кырлар, игенлекләр тәмам кардан ялангач калып, карала башладылар.

Менә бераздан сабан туе җитте. Мине сабан туе көнне иртүк уятып, кулыма янчык дәрәҗәсеннән аз гына үткән кечкенә бер капчык тоттырдылар.

Мин, шул капчыкны тотып, авыл буенча киттем.

Авыл халкы тегеләй дә иртә торучан булса да, бүген сабан туе бәйрәме көне булганга, бигрәк тә иртә торганнар вә һәр өйдә, һәркемдә көләч йөз, тәмле сүз иде.

Мин кайсы гына өйгә керсәм дә, минем ятим калган мулла баласы икәнемә игътибарән, миңа, башка малайларга биргән кеби, конфет, бер-ике перәннек кенә бирмичә, һәр йорт иясе дә буяган күкәй бирәләр иде.

Шунлыктан минем капчыгым буяган күкәйләр илә бик тиз тулып, өйгә дә кайтып кердем. Башка малайлар һаман йөреп калдылар шикелле.

Әти белән әни дә минем капчыкның болай тиз тулуына гаҗәпләнделәр дә, шатландылар да.

Ул көнне чәй эчтемме, юкмы – анысын белмим; капчыкны әнигә бирдем дә, үзем, кулыма берничә күкәй тотып, урамга чыгып чаптым.

Мин урамга чыкканда, кояш күтәрелгән, бөтен авыл нурланган, авыл егетләре, авыл кызлары ак оекларын мөмкин кадәр шомартып киеп, чабата киндерәләрен дә бик тырышып, матурлап бәйләп, урамга чыкканнар иде.

Бер яктан сабан туе башлыгы да, кулына бер таяк башына чүпрәк таккан әләм тотып, өй саен яулык, ситсы кеби нәрсә җыеп йөри иде. Без – яланаяклы малайлар исә аның артыннан бер дә калмыйча йөгерә идек.

Чүпрәкләр, яулыклар җыелып тәмам булгач, бөтен авыл халкы – хатыны-кызы, баласы-чагасы болынлыкка төштеләр. Көрәшләр, узышулар башланды. Болынлыкта йөк-йөк белән торган чикләвек, көнбагыш вә кызыл билле ак перәннекләр хисапсыз иде.

Болар арасында егетләр тарафыннан кызларга бирелергә иң муафигы, әлбәттә, кызыл билле ак перәннек инде. Чөнки ул перәннек хакында бер авыл җыруы да бар. Болай:



Рәссам Светлана ПРИВИНА

Болынлыкка бөркет килгән,
Куркытадыр казларны;
Кызыл билле ак пәрәннек
Кызыктыра кызларны.

Атлар да чабышты, малайлар да йөгереште, яулыклар да алынды; шулай итеп, сабан туе да бетте.

Исемдә юк инде – бу сабан туе ничә көн булгандыр, мин бер көнен генә яздым. Бәлки, ул 3-4 көн булса да, миңа бер генә көн кеби тоелгандыр.

Шуны да әйтергә кирәк: мин бу җәйне үткән җәй кеби йөгереп, уйнап үткәрә алмадым. Чөнки шушы язга чыгар алдыннан гына Сәгъди абзыйның бер ир баласы дөньяга килгәнгә, мин, әни эштә чагында, һәрвакыт шул баланы юатып, тирбәтеп утыра идем.



Вакыйф НУРИЕВ

Шүрәле

(Хикәя-табышмак)

Самат белән әнисе – икесе генә яшиләр. Әнисе район үзәгенә йөреп эшли. Иртән иртүк китә, кич соң гына кайта. Самат өченче сыйныфта укый. Укуы төштән соң. Әнисе аңа: «Кечкенәдән эшкә өйрәнеп үсәргә кирәк», – дип тукып тора. Менә бүген дә кәҗә белән сарыкка печән салырга кушып китте. Әнисе киткәч, малай рәхәтләнеп йокы симертте. Уянды. Ни саран кышкы кояш инде, ул да өйне нурга күмгән. «Әйдә, Самат, уйнарга», – дип әйтүедер инде, тәгаен. Тик менә дәрескә әзерләнәсе бар. Әй, качмас өйгә бирелгән эш. Самат урамга сызды. Кәҗә белән сарыкка да печән салып мәшәкатьләнмәде. «Ачтан үлмәсләр әле. Эшкә исә үскәч тә өйрәнергә була. Ул кәҗә белән сарыгын әйтер идем инде. Ничу ашатып яткырырга аларны?! Чыгарасы да җибәрәсе. Үз көннәрен үзләре күрсеннәр. Беткәнмени ферма тирәсендә ат чанасыннан коелып калган печән, сенаж-менаж, силос-милос. Йөрсеннәр шунда чемченеп». Малайның башында менә шундый уйлар кайнады.

Самат дусты Фәритләргә барып компьютерда уйнады. Аннары өенә кайтып, китап-дәфтәрләрен алды да мәктәпкә чыгып чапты. Ач кәҗә аны, абзар тәрәзәсеннән башын тыгып, моңсу гына озатып калды.

Малай мәктәптән кайтканда авыл ут алган иде инде. Малай курка-курка атлады. Тынлык. Җир йоклый әле, ак юрганын ябынып. Тизрәк яз җитсен, кошлар кайтсын иде. Җир уяныр иде. Саматларның өе авылның иң читендә булып, кайтып җитәрәк зireклекне үтәсе бар. Малай ул төштән бигрәк тә шүрли. Агачлар, ботак-сатаклар арасыннан Шүрәле килеп чыгар кебек. Их, нишләп кояш төнлә дә балкымый икән?! Ай куып җибәрәдер аны. Ай һәм Кояш. Алар гел тарткалашып, ызгышып яшиләрдер кебек тоела Саматка.

Малай зиреклекне исән-имин генә үтте. Кайтып җитеп, капка келәсенә үрелгән иде, ишегалдында кар шыгырдаган тавыш аны сагаерга мәҗбүр итте. Кем булыр? Әнисе эштән соң кайта. Өйдә ут юк. Шулай да йөрәксенеп капканы ачты. Ачса... Абау!.. Самат капканы кире япты да урам буйлап чабып китте. Ишегалдында күргәнен ул һаман әле башына сыйдыра алмый иде. Нәрсә булыр ул? Ике аягына баскан да тәрәзәгә сузылган. Өй эчен күзәтә. Ак төстә. Бөтен тәне чат җон гына. Билендә җиргә кадәр асылынган шома капчык. Маңгаенда мөгезе дә бар иде бугай. Шүрәле шушы түгелме соң инде?! Саматларның өендә ни калган аңа?

Шүрәлене күрергә ярты авыл җыелды. Тик аның көн буена ач яткач, абзар тишегеннән шуышып чыгып, өй тәрәзәсенә печән өмет итеп сузылган бичара кәҗә булуы бик тиз ачыкланды. Капчыгы исә буш җилене икән. Эшкә иренгән Самат оятыннан, хурлыгыннан кәҗә шуышып чыккан шул тишеккә кереп качардай булды.



Рәссам Иван ВОРОБЬЕВ

КАДЕРЛЕ ДУСЛАР!

Язучы бу хикәяне язганда Габдулла Тукайның 2 әкиятен, 8 шигырен күздә тоткан. Алар ничек атала? Хикәя герое Самат аларның кайсын укыган, кайсын укымаган? Дөрес җавап җибәрүчегә бүләк бар.



«Без – Тукай шәкертләре»

Ярдәмеңнән ташлама, дим...

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап,
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап.
Шулвакыт безнең каршыга килеп чыкты бер бүре...
Исем китте: янып тора, ялтырый ике күзе.
Мондый авыр хәлләрдә гел юк иде бит калганым,
«Казанга җитеп булмас бит!» – уйлый алмыйм калганын.
Болай булгач, булмас инде, хуш, Казан, нурлы Казан!
Ишетелә кебек миңа синдә яңгыраучы азан.
Эчтән генә укыймын мин белгән догаларымны,
«Ярдәмеңнән ташлама, – дим, – Ходам, балаларыңны».
Кабул булды бугай догам, кинәт үзгәрде бүре,
Тыныч кына китеп барды килгән юлыннан кире.
Күңелемә шатлык тулды, күздә ялтырый яшьләр,
Нурлы һәм моңлы Казанда көтә мине зур эшләр.

Әйт әле, Шүрәле

Әкиятләр арасында
Иң кызыгы – «Шүрәле»:
Маңгаендагы мөгезе
Нинди матур, күр әле!

Төшләремә керәдер ул,
Озын бармагын сузып.
Уйный торгач кети-кети,
Ничек бетмидәр тузып?

Күңелсезме, әйт, Шүрәле,
Берүзеңә урманда?
Төннәрен килеп авылга
Йөрисеңме урамда?

Әни дә сабый чагында
«Шүрәле» укып үскән.
Балама шул әкиятне
Сөйләрмен мин дә үскәч.

Алисә ШӘЙХӘЙДӘРОВА, 10 яшь.
Мөслим, Сикия.



Габдулла ТУКАЙ

Сабыйга

Һич сине куркытмасыннар шүрәле, җен һәм убыр;
Барчасы юк сүз – аларның булганы юктыр гомер.
Җен-фәлән дип сөйләшүләр искеләрдән калган ул;
Сөйләве яхшы, күңелле – шагыйранә ялган ул.
Һич өрәк, албасты булган сахралар, кырлар да юк;
Шүрәле асрап ята торган кара урман да юк.
Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын;
Мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын.

Ребенку

Дружок, не бойся шурале, ведьм не бойся и чертей,
Никто, поверь мне, отродясь не встречал таких гостей.
Такие вымыслы, дружок, – лишь туман былых времен;
Не устрашает, а смешит нас шайтан былых времен.
Для упыря нет пустыря, логова для беса нет;
Для недотепы шурале девственного леса нет.
Так постарайся же, дружок, все науки изучить
И вскоре правду ото лжи ты сумеешь отличить.






Безнен гаилә

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи –
Безнең өйдә без җидәү: безнең песи – җиденчесе.
Бергә ашый, чәй эчә, безнеңлә бергә йоклый ул,
Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан саклый ул.

Наша семья

Папа с мамой, баба с дедом, кошка, и сестра, и я –
Семь нас в доме, и седьмая – кошка славная моя.
Кошка с нами ест и пьет, с нами вместе спать идет.
И работа есть у кошки – дом от мышек стережет.





Гали белән Кәҗә

Безнең Гали бигрәк тату Кәҗә белән,
Менә Кәҗә карап тора тәрәзәдән.
Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә.

Гали и Коза


С Козою дружит наш Гали который год.
Он вместе с ней гулять идет на огород.
Свою Козу там угощает он травой,
Ну а Коза трясет довольно бородой.

Кызыклы шәкерт

– Әйдәле, Акбай! өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума! туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!
– Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр, йә өч кенә.
Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә;
Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.
– Ах, җүләр маэмай! Тырыш яшьләй, – зурайгач җайсыз ул;
Картаеп каткач буыннар, эш белү уңгайсыз ул!

Забавный ученик

– Стой, Акбай, на задних лапках, поучись-ка, послужи!
Ну, не падай! Ну, не падай! Спину ровненько держи.
– Мне учение – в мученье! Я же маленький, – смотри!
Сколько от роду мне... Месяц? Или два? А может, три...
Мне ли службой заниматься, мне бы, хвост задрав, помчать!
Мне б на травке поваляться, научиться бы рычать!
Глупый пес не разумеет – нет уж, сызмала учись!
Кости к старости твердеют, не согнешься, как ни гнись!





Рәссам
Диләрә НӘҮРҮЗОВА

Кәҗә белән Сарык

(Тукай әкиятен дәвам итеп)

Бүреләр куркудан бу урманны ташлап китәләр.

Кәҗә белән Сарык иркенләп яши башлыйлар. Урманда җиләк-җимеш, гөмбә, чикләвек күп була. Алар шуның белән тукланалар, сусыл үләнне дә туйганчы ашыйлар – бик тиз көрәеп китәләр. Көз җиткәч, бер капчык чикләвек җыеп, әби белән бабай янына кайталар.

Әби белән бабай бик сөенә инде. Тәмле чикләвекне туйганчы ашыйлар. Калганнарын сатып, акчасына ипи һәм печән алалар. Бу ризыклар әби белән бабайга да, кәҗә белән сарыкка да ел беткәнче җитә.

Яңа елда исә шатлыклы хәбәр килә: әби белән бабайның пенсияләрен арттыралар!

Хәзер инде алар интегеп яшәмиләр: маллары да тук, үзләре дә шат.

Илшат КӘРАМОВ, 8 яшь.
Яр Чаллы.



Илназ НОТФУЛЛИН.
Саба, Тимершык.



Румия НИГЪМӘТҖАНОВА, 13 яшь.
Мөслим, Митрәй.

Ләбиб ЛЕРОН

Нәни Апуш әкият сөйли

(Балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр һәм кече яшьтәге мәктәп укучылары өчен)

Алып баручы:
Нәкъ Казанның артында –
Әтнә, Арча ягында, –
Яшәгән, ди, бер малай
Кырлай дигән авылда.
Исем-аты Габдулла
Булган икән малайның:
Үз итеп, Апуш дип тә
Йөрткәннәр бу баланы.
Габдулла әкиятләр
Сөйләргә яраткан, ди:
Тыңлаучыларның барсын
Аузына караткан, ди...
Габдулла (Апуш).
Баллы икән алмагыз,
Әче икән тормагыз!..
Чын әкиятләр сөйлим –
Авыз ачып тормагыз!
Бер бала (Гали).
Сөйлә, син, Апуш, сөйлә,
Безнең тыңлыйсы килә!
Габдулла.
Беркөнне барам шулай,
Баскан эздән пар чыга...
Кинәт шулчак биш куян
Килде-чыкты каршыма!


Кишер тоткан «куяннар» пәйда була.

Гүя минем килүемне
Көтеп торган куяннар:
Миңа «куян кучтәнәче»
Әзерләп үк куйганнар...
– Синең, Габдулла дускай,
Беләгең тимер, – диләр, –
Мә, сиңа – кишер, – диләр, –
Бик тәмләп кимер! – диләр...

«Куяннар» Габдуллага һәм башка балаларга кишер бирәләр дә биеп алалар.

Икенче бала (Сабит).
Булыр, булыр, ышанам,
Бу хәл – чынга охшаган!
Өченче бала (Фатыйма).
Габдулла, тагын әйдә,
Күргәннәреңне сөйлә!
Габдулла.
Эһем... Эһем... Бервакыт
Карурманда йөрдем мин...
Беләсезме, мин анда
Гаҗәп хәлләр күрдем мин!
Барам шулай җай гына...
Тукта! Ни бу? Күр әле! –
Килеп чыкты каршыма...
Килеп чыкты... Шүрәле!
Дүртенче бала (Ламига).
Кит аннан! Булмас, булмас...
Арттырмале шулчаклы!

«Шүрәле» пәйда була. Ул, тыңлаучыларга күренмәскә тырышып, алар артында төрле хәрәкәтләр ясап, уйнап-кыланып йөри.



Бишенче бала.
Син, Апуш, күзгә карап,
Күп сибәсең борчакны!
Сабит.
Булыр, булыр, ышанам,
Бу хәл – чынга охшаган!
Габдулла.
Борчак сипмим, алдашмыйм –
Сүземдә юк һич ялган:
Чын әкият сөйлим, дип
Әйтеп куйдым ич алдан...
Гали.
Сөйлә, син, Апуш, сөйлә,
Безнең тыңлыйсы килә!
Габдулла.
Борын-борын заманда
Булган икән бер малай...
Сөйләп тә тормам әле
Тавышлансагыз алай!
Бишенче бала.
Бетте, бетте, Габдулла,
Тавышланмыйбыз бүтән!
Фатыйма.
«Шүрәле»ңнең дәвамын
Көтәбез инде күптән!
Габдулла *(«Шүрәле»гә карап сөйли).*
Шуннан шул... Шүрәлегә
Мин әйтәм: «Мин – Былтыр! –
дим, –
Минә шушы ярыкка
Бармагыңны кыстыр!» – дим...

«Шүрәле» Габдулла күрсәткән агач ярыгына бармакларын кыстыра.



Бер агарды Шүрәле,
Бер кызарды Шүрәле,
Бер кабарды Шүрәле,
Авыз ачты Шүрәле...
«Кети-мети уйныйк!» – дигәч,
Куркып качты Шүрәле.
Шүрләде!

«Шүрәле», агачны култык астына кыстырып, ах-ух килеп, чыгып китә.

Гали.
Вәйт, әкәмәт!
Фатыйма.
Вәйт, мәзәк!
Ламига.
Гаҗәп дисәң дә гаҗәп!
Сабит.
Булыр, булыр, ышанам,
Бу хәл – чынга охшаган!
Бишенче бала.
Шыттырасың, Габдулла,
Арттырмасаң да була!
Габдулла
(Бишенче балага карап).
Борын-борын заманда,
Яшәгән, ди, бер торна...
Әкият сөйлим, дидем бит –
Игътибар белән тыңла!

Барам шулай бервакыт
Базарга – Мәкәрҗәгә...
Шулчак юлда юлыктым
Сарык белән Кәҗәгә!

«Кәҗә» белән «Сарык» пәйда була.

Кәҗәсе ябык иде,
Сарыгы арык иде.
Сарыгы капчык аскан –
Капчыгы ярык иде.
Гайрәтләнеп, мактанып,
Капчык аузын ачтылар:
Бер-бер артлы бүреләр
Шуннан чыгып качтылар...
Иренмәдем, санадым:
Унике бүре иде...
Унысы – исән иде,
Икесе тере иде!

«Кәҗә» белән «Сарык» «бүреләр»не куып йөриләр – уенны төрле кызыклар белән баетырга була.

Сабит.
Бу хәл – чынга охшаган!
Гали.
Хәтта мин дә ышанам!
Габдулла.
Сине дә тыңлыйк әле –
Әйдә, син сөйлә, Гали!?
Гали.
Мин бүген кәҗәбезгә
Бер кочак печән бирдем.
Ул, сакалын селкетеп:
«Зур рәхмәт, Гали! – диде. –
Ашап, йоклап алгачтын,
Икәү балык тотарга
Барырбыз әле!» – диде...
Сабит.
Гали, син дә – маладис!
Борчак сибә беләсең...
Ламига.
Габдулла шәбрәк сөйли!..

Фатыйма.
Әйдә, Апуш, сөйләсен!
Габдулла.
Борын-борын заманда,
Булган икән бер мичкә.



Ярар инде – җитеп торыр,
Сөйләрмен әле кичкә.
Мин сөйләрмен бер әкият –
«Су анасы» турында.
Хәзер, әйдә, ял итик –
Туктыйк шушы урында...

Балалар теләр-теләмәс кенә таралышалар яки берәр кызыклы уен уйный башлыйлар.

Алып баручы.
Нәни Апуш әкиятләр
Сөйләр әле тагын да...
Дәү булгач та, ул еш кайтыр
Шул самими чагына.

Хыял аша еш кайтыр ул –
Балачагын сагынып:
Күңелендә сагыш-моңнар
Шигырь булып кабыныр!

Еллар узар...
Нәни Апуш
Зур шагыйрь – ТУКАЙ булыр:
Халкыбызның йөрәгенә
Тоташыр гомер юлы.

КАДЕРЛЕ ДУСЛАР!
Ошбу әкияти тамашада катнашкан Гали, Сабит, Фатыйма һәм Ламига исемнәре Габдулла Тукайның кайсы әсәрләрендә очрый? Йә, кем тизрәк әйтә?

Рәссам Алла АЙСИНА



Табышмак әйтәм... Сорау бирәм...



Табышмакның җавапларын
Эзләмә әллә кайдан.
Укысаң әгәр тырышып –
Тиз табарсың Тукайдан.

Кәҗә белән сарыкның капчыгында
ничә бүре башы булган?

Пар атларны җиктереп арбага,
Чыгып киткән Казан дигән калага.
Ул кем?

Шар яра, ди, бар урманны җыеп,
Кысканга Былтыр кычкыра быел.

Кайда ул безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Кайда соң дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.
Кайсы шәһәрдә?

Сачен тарап алтын тарак белән
И бизәнә, ясана.
Вә шуннан соң кинәт суга чума –
Нәрсә кала басмада?

Җәй көне. Эссе һавада ул суда койна, йөзә;
Чәчрәтә, уйный, чума, башы белән суны сөзә.
Ул нинди малай?

Дөньяда күп нәрсә белдең син нинди тел аркылы?

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Әти-әни өчен баласының казага таруыннан да авыр хәл юк! Юлдагы фаҗига... һәм башка имгәнүләр... Тормышыбызда адым саен болар! Аллам сакласын!!! Хәер, Ходай да саклanганны гына саклармын, дигән.

Бу уңайдан махсус программа бар. Шул нигездә без дә яңа сәхифә ачып җибәрәбез.

Уйлашыйк, фикерләшик. Киңәшле эш таркалмас, диләр.

Сәхифәне Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Айрат ЗИННУРОВ алып бара

Былтыр гына республикабыздагы юл фаҗигаләрендә 22 бала һәлак булган. 771е имгәнгән. Күпме хәсрәт, кан, күз яше...

Балаларның юл фаҗигасенә дучар булуларының төп сәбәпләре:

– юлны җәяүлеләр өчен билгеләнгән урыннан чыкмау.


– юлга машиналар артыннан, автобус, троллейбуслар алдыннан, өй почмагыннан көтмәгәндә килеп чыгу.

– 7 яшькә кадәрге балаларның урамда үзләре генә йөрүе.

1998 елда Татарстанда мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен махсус программа да булдырылды. Аның төп өлешен «Шәһәр урамында – бала» бүлеге алып тора. Аның нигезендә балалар бакчаларында ГИБДД вәкилләре белән бергә төрле бәйрәмнәр, КВНнар, ярышлар, ата-аналар җыелышлары үткәрелә.

Ике елга бер тапкыр безнең министрлык Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе белән бергәләп шәһәрдә һәм авыл җирендә балалар, тәрбиячеләр арасында конкурслар да үткәрә.

«Бала!Бәла-каза» сәхифәсендә сан саен сабыйлар имгәнүдә гаепле булган өлкәннәрнең исемнәрен атарбыз. Чөнки бу фаҗигаләрдә бары тик без, өлкәннәр генә, гаепле! Бу мәсьәләгә салкын караган һәр мәгариф оешмасы, һәрбер мәктәп «Салават күпере»ндә акка кара белән язылып барылачак!



Сыбызгы

(«Юлга чыксаң...»)

Әниләр күз яше түкмәсен

Һәркем өчен кирәк нәрсә –
Белү юл кагыйдәсен.

Әйе, дөресе дә шул – юл кагыйдәләрен белмичә торып, капка төбенә дә чыга алмыйсың. Менә без авыл җирендә яшибез. Капка төбеннән үк асфальт юл уза. Бу инде – һәр кеше юл кагыйдәсен белергә тиеш, дигән сүз.

Әйдәгез, юлларда уйнамыйк, машиналар белән узышмыйк, велосипедта яки җәяү йөргәндә юл кагыйдәләрен төгәл үтик. Әти-әниләрне, укытучыларыбызны борчуга салмыйк. Алар күз яшьләрен түкмәсеннәр. Ашыкмыйк, игътибарлы булыйк! Шул вакытта һәркайсыбыз тыныч булыр.



Раил ГАЛИЕВ, 9 яшь.
Арча, Ташкичү.

Сәлават күпере

3(192) — 2006

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЖИР, МИЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.
1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РТ, ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.
Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Диләрә НӘҮРҮЗОВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта рәссам Х. КАЗАКОВның «Бәләкәй Тукай» картинасы һәм Фәрит МУЛЛАХМӘТ рәсеме

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: ck-sxn@newmail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиесе.
Казан, Декабристлар урамы,2 нче йорт.
Производствога бирелде 3.03.2006 ел.
Басарга кул куелды 3.03.2006 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тираж 11629 данә. Заказ 3-154.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хөснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Р. Зәйдулла, Н. Шаһиев, Н. Акмал, З.Вакказова, Г. Сабирова.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

ГабдуллаТукай

Бала белән Күбәләк

Бала:
Әйт әле, Күбәләк,
Сөйләшик бергәләп:
Бу кадәр күп очып,
Армыйсың син ничек?

Ничек соң тормышың?
Ничек көн күрмешең?
Сөйләп бирче тезеп,
Табаламсың ризык?

Күбәләк:
Мин торам кырларда,
Болында, урманда;
Уйныймын, очамын
Якты көн булганда.

Иркәли һәм сөя
Кояшның яктысы;
Аш буладыр миңа
Чәчәкләр хуш исе.

Тик гомрем бик кыска:
Бары бер көн генә, –
Бул яхшы, рәнҗетмә
Һәм тимә син миңа!

